**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений**
**в Закон Республики Татарстан «О недрах»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 ноября 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 декабря 1992 года № 1722-XII «О недрах» (в редакции Закона Республики Татарстан от 6 декабря 1999 года № 2486) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1992, № 11 – 12; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I часть); 2005, № 4 (I часть); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I часть), № 12 (II часть); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2018, № 22 (часть I) следующие изменения:

1) статью 16 дополнить абзацем следующего содержания:

«о предоставлении права пользования участком недр местного значения для добычи подземных вод, используемых для целей хозяйственно-бытового водоснабжения садоводческих некоммерческих товариществ и (или) огороднических некоммерческих товариществ.»;

2) часть вторую статьи $35^1$ дополнить абзацем следующего содержания:

«добыча подземных вод, используемых для целей хозяйственно-бытового водоснабжения садоводческих некоммерческих товариществ и (или) огороднических некоммерческих товариществ.»;

3) в части второй статьи $35^3$ цифры «$35^{8.1}$» заменить цифрами «$35^{8.2}$»;

4) дополнить статьей $35^{8.2}$ следующего содержания:

«Статья $35^{8.2}$. **Документы, необходимые для предоставления права пользования участком недр местного значения для целей хозяйственно-бытового водоснабжения садоводческих некоммерческих товариществ и (или) огороднических некоммерческих товариществ**

Для предоставления права пользования участком недр местного значения для целей хозяйственно-бытового водоснабжения садоводческих некоммерческих товариществ и (или) огороднических некоммерческих товариществ необходимы документы, предусмотренные абзацами вторым – пятым части первой статьи $35^2$ настоящего Закона, а также:

документ об уплате государственной пошлины за предоставление лицензии на пользование недрами;

копия топографического плана участка недр местного значения, предоставляемого в пользование (в трех экземплярах);

информация об участке недр местного значения, предоставляемом в пользование, содержащая сведения, указанные в части второй настоящей статьи;

копия паспорта водозаборной скважины;

расчет и обоснование заявленного объема добычи подземных вод;

копия санитарно-эпидемиологического заключения о соответствии водного объекта санитарным правилам и условиям безопасного для здоровья населения использования водного объекта.

Указанная в абзаце четвертом части первой настоящей статьи информация об участке недр местного значения, предоставляемом в пользование, должна содержать:

сведения о применении системы водоподготовки (при наличии);

схему водозабора, географические координаты скважин, расположенных на участке недр;

сведения о конструкциях и назначении скважин, расположенных на участке недр;

характеристику режима эксплуатации водозаборного сооружения;

сведения об имеющихся средствах учета и контроля за количеством и качеством добываемых подземных вод;

обоснование возможности добычи подземных вод в объеме заявленной потребности на участке недр.

Документы, предусмотренные абзацем вторым части первой статьи $35^2$ настоящего Закона, абзацами вторым – шестым части первой настоящей статьи, представляются заявителем одновременно с подачей заявки.

Документы, предусмотренные абзацами третьим – пятым части первой статьи $35^2$ настоящего Закона, абзацем седьмым части первой настоящей статьи, запрашиваются органом управления государственным фондом недр самостоятельно, если заявитель не представил указанные документы по собственной инициативе.

Копии документов должны быть заверены в установленном порядке либо представлены с предъявлением оригиналов.»;

5) в статье 92:

а) в части первой слова «Проектирование и строительство населенных пунктов, промышленных комплексов и других хозяйственных объектов» заменить словами «Строительство объектов капитального строительства на земельных участках, расположенных за границами населенных пунктов, размещение подземных сооружений за границами населенных пунктов»;

б) в части второй слово «площадей» заменить словами «земельных участков, которые расположены за границами населенных пунктов и находятся на площадях», слова «в местах их залегания» заменить словами «за границами населенных пунктов в местах залегания полезных ископаемых».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2019 года, за исключением абзаца четвертого пункта 4 и пункта 5 статьи 1 настоящего Закона.

2. Пункт 5 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу со дня его официального опубликования.

3. Абзац четвертый пункта 4 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу с 1 января 2020 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
30 ноября 2018 года
№ 95-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Җир асты байлыклары турында”**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләрен һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләрен хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында.”;

2) $35^1$ статьяның икенче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләрен һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләрен хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын чыгару.”;

3) $35^3$ статьяның икенче өлешендә “$35^{8.1}$” саннарын “$35^{8.2}$” саннарына алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $35^{8.2}$ статья өстәргә:

“$35^{8.2}$ статья. **Бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләрен һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләрен хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен кирәкле документлар**

Бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләрен һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләрен хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы икенче – бишенче өлешләрендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр дә кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү турындагы документ;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

әлеге статьяның икенче өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында мәгълүмат;

су чыгару скважинасы паспорты күчермәсе;

җир асты суларын чыгаруның күрсәтелгән күләмен исәпләп чыгару һәм нигезләү;

су объектыннан халык сәламәтлеге өчен зыянсыз файдалануның санитар кагыйдәләренә һәм шартларына су объектының туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе.

Әлеге статьяның беренче өлешендәге дүртенче абзацында күрсәтелгән файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турындагы мәгълүматта түбәндәгеләр булырга тиеш:

су әзерләү системасын куллану турында белешмәләр (булган очракта);

су җыю схемасы, җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналарның географик координаталары;

җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналарның конструкцияләре һәм билгеләнеше турында белешмәләр;

су җыю корылмасын эксплуатацияләү режимының характеристикасы;

чыгарыла торган җир асты суларының күләмен һәм сыйфатын исәпкә алуның һәм тикшереп торуның гамәлдәге чаралары турында белешмәләр;

җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты суларын күрсәтелгән ихтыяҗ күләмендә чыгаруның мөмкин булуын нигезләү.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешнең икенче абзацында, әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – алтынчы абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бер үк вакытта тапшырыла.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең өченче – бишенче абзацларында, әлеге статьяның беренче өлешендәге җиденче абзацында каралган документларны, әгәр мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны үз

инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы үзе соратып ала.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга йә төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырылырга тиеш.”;

5) 92 статьяда:

а) “Торак пунктларны, сәнәга комплексларын һәм башка хуҗалык объектларын проектлау һәм төзү” сүзләрен “Торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан җир кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү, җир асты корылмаларын торак пунктлар чикләреннән читтә урнаштыру” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә беренче җөмлә башына “Торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан һәм” сүзләрен өстәргә, “мәйданнарда” сүзен “мәйданнардагы җир кишәрлекләрендә” сүзләренә алмаштырырга, “алар яткан урыннарда” сүзләрен “файдалы казылмалар яткан урыннардагы торак пунктлар чикләреннән читтә” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 4 пунктының дүртенче абзацыннан һәм 5 пунктыннан тыш, 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 5 пункты рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының дүртенче абзацы 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 30 ноябрь
№ 95-ТРЗ